| Республика Татарстан<br>Исполнительный комитет<br>Чукмарлинского сельского<br>поселения Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Чукмарлы авыл җирлеге<br>башкарма комитеты |
|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |
|---|---|
| 19 декабрь 2025 ел | № 22 |

**2026 елга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль буенча закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасын раслау турында**

"Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон , Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) куркынычларын профилактикалау программасын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында" 2021 елның 25 июнендәге 990 номерлы карары нигезендә, "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау турында" 2021 елның 26 ноябрендәге 13 номерлы Чукмарлы авыл җирлеге Советы карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге башкарма комитеты

**карар итә:**

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль буенча закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасын расларга (1 нче кушымта)
2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru/.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.